Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Васильевка авыл Советы

КАРАРЫ

14 декабрь 2023 ел № 90

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Васильевка авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының 2013 елның 25 ноябрендәге 68 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге икенче өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Васильевка авыл җирлеге Уставының 28 статьясы нигезендә,

Васильевка авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Васильевка авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Васильевка авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 68 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Васильевка авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 92 номерлы, 2015 елның 5 маендагы 109 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 77 номерлы, 2020 елның 18 ноябрендәге 6 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары билгәгән җир кишәрлекләренә карата (күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган җир кишәрлекләреннән тыш) яисә эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) 0,3 процент.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Васильевка авылы, Үзәк урам, 26 йорт, Улаклы Чишмә авылы, Үзәк урам, 32а йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 01 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл Советы башлыгына йөкләргә.

Васильевка авыл
җирлеге башлыгы Ш.М.Касыймуллин